**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**17 апрель 2019 ел** **№ 287**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 13 иче апрель 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәте турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 ел, 2 нче март, 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, 2013 ел, 25 нче июнь, 50-ТРЗ, “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү турында”, 2018 ел, 6 нчы октябрь, 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 статьясына үзгәрешләр кертү турында” 2019 ел, 1 нче март, 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 13 нче апрель 138 номерлы карары белән расланган (2017 ел, 13 нче октябрь 168 номерлы, 2018 ел, 28 нче март 202 номерлы, 2018 ел, 11 нче июль 226 номерлы, 2018 ел, 31 нче август 238 номерлы карарлардагы үзгәрешләрен кертеп) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәте турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 7.2.1 пункты белән тулыландырырга:

«7.2.1. Гражданин рәис урынбасары һәм муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый, муниципаль хезмәткәр рәис урынбасары һәм муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы аудиторы вазыйфаларын, билгеле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, Башкарма комитет җитәкчесе, суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлык яисә охшашлык (әти-әниләр, ир белән хатын, балалар, ир туганнар, кыз туганнар, шулай ук хәләл җефетнең ир туганнары, кыз туганнары, әти-әниләре, балалары һәм балаларның хәләл җефетләре) булганда алыштырып тора алмый.»

2) 7 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 7.4. пункты белән тулыландырырга:

«7.4. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыкмасын өчен, муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен, әлеге җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында күрсәтелгән вазыйфаны алыштырып торган вакытта тәкъдим итә алмый.;.»

3) 8 бүлекнең 8.1 пункты 2 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхсән үзе яки ышанып тапшырган затлар аркылы эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә катнашырга яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итәргә (сәяси партияләр белән идарә итү очрагыннан, түләүсез формада һөнәри союз органы идарәсендә, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланган органында; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма гомуми җыелышында, торак, торак төзелеше, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллану кооперативы, милек хуҗалары ширкәтендә катнашу мөмкинлегеннән кала), күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмаларның (сәяси партия һәм һөнәри союз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайланган органыннан кала) идарәсендә тәүләүсез нигездә бердәнбер башкару органы сыйфатында яки аларның идарә итү коллегиаль органына эшкә алучы (эш бирүче) рөхсәте белән, муниципаль норматив хокукый акт нигезендә алынган тәртиптә керү, түләүсез нигездә, муниципаль берәмлек учредителе (акционер, катнашучы) булган муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен, муниципаль берәмлек исеменнән оешманың учредителе яки муниципаль милкендә булган акцияләр белән идарә итү (устав капиталында булган катнашу өлешләре) тәртибен ачыклаучы муниципаль хокукый актлар нигезендә, идарә органында һәм оешманың ревизия комиссиясендә тәкъдим итүдән кала; федералҗ законнар белән билгеләнгән башка очракларда;»;

4) 23 бүлекнең 23.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1 подпункты белән тулыландырырга:

2.1) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе докладлары, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең бары тик аның ризалыгыннан гына язмача аңлатмалары һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатуы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүдән тыш)»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр буенча комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин